**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Пестречинского**
**муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы**
**Питрәч муниципаль**
**районы**
**башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Совет урамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02 факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«06» март, 2025 ел

№ 121-п

«Су белән тәэмин итү, су бүлеп бирү һәм аның эшчәнлек зоналарын гарантияләүче оешманы билгеләү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 февралендәге 124 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү турында» 2011 елның 07 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль законның 6, 12 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. «Су белән тәэмин итү, су бүлеп бирү һәм аның эшчәнлеге зонасын гарантияләү оешмасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 20 февралендәге 124 номерлы карарының 2 пунктына үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының түбәндәге торак пунктлары территориясе гарантияләүче оешманың эшчәнлек зонасы булып тора: Питрәч авылы, Олан Иле авылы, Шихазда авылы, Олы Дүртөйле авылы, Колай авылы, Тогашево авылы, Ленино-Кокушкино авылы, Олы Бутырка авылы, Салкын Чишмә авылы, Кощаково авылы, Иске Кощаково авылы, Званка авылы, Барановка авылы, Пановка авылы, Новоселок авылы, Иске Шигали авылы, Яңа Шигали авылы, Татар Тау Иле авылы, Княжа авылы, Янсуар авылы, Раевка авылы, Нырсуар авылы, Талкыш авылы, Надеждино авылы, Петрово авылы, Урта Ия авылы, Белкино авылы, Чертово авылы, Богородский авылы, Гильдеево авылы, Ильинский поселогы, Камыш авылы, Беренче Май поселогы, Черниково авылы, Пимәр авылы, Юныс авылы, Татар Казысы авылы, Кибәч авылы, Кәвәл авылы, Күн авылы, Әлбәдән авылы, Кызыл Яшьләр авылы, Арышхазда авылы, Чыты авылы, Иске Йорт авылы, Керәшен Сәрдәсе авылы, Көлкәмәр авылы, Шәле авылы, ТатЦИК исемендәге авыл, Екатериновка авылы, Александровка авылы, Югары Дәүләзәр авылы, Нептун авывлы, Утра Дәүләзәр авылы, Көек авылы.

3.Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Светлый» ТКда су

белән тәэмин итү, су бүлеп бирү буенча гарантияләүче оешманы билгеләү турында» 2021 елның 23 июлендәге 461 номерлы, «Яшьлек» ТК территориясендә су белән тәэмин итү һәм су бүлеп бирү буенча гарантияләүче оешманы һәм аның эшчәнлек зонасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2024 елның 02 августындагы 542 номерлы карарлары үз көчләрен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Р. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Муниципаль район
башкарма комитеты җитәкчесе И.Р. Дәүләтханов